РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024г. г. Альметьевск №147

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләүгә ышанычсыз дип тануны 2024 елның 1 январена аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 январена кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 һәм (яисә) 70 статьяларында билгеләнгән сроклар узгач 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Бурычны суммалар өлешендә түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 6 июлендәге 112 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов